КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1172

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 ноябрь, 1000 нче, 2020 ел, 25 февраль, 144 нче, 2021 ел, 2 апрель, 208 нче, 2022 ел, 14 февраль, 125 нче, 2023 ел, 14 март, 242 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына (алга таба – Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасының II бүлегендә:

«Төбәк программасы максатлары» юлының икенче графасында «95,03» һәм «98,34» саннарын тиешенчә «95,641» һәм «98,782» саннарына алмаштырырга;

«Төбәк программасында катнашучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» юлының икенче графасына «, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы» сүзләрен өстәргә;

«Гамәлгә ашырыла торган чаралар» юлының икенче графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү»

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Суровка һәм Новотроицкое авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме»</td>
<td>2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 2 248 668,75 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td>Ел</td><td>Барысы</td><td colspan="3">Шул исәптән</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td><td>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>бюджеттан тыш акча</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>80 444,72</td><td>4 822,0</td><td>20 556,82</td><td>55 065,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>54 134,45</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>54 134,45</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>274 548,27</td><td>26 391,58</td><td>112 510,88</td><td>135 645,81</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>897 207,07</td><td>148 018,98</td><td>631 028,3</td><td>118 159,79</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>755 357,19</td><td>107 992,29</td><td>460 387,9</td><td>186 977,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>186 977,05</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>186 977,05</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 248 668,75</td><td>287 224,85</td><td>1 224 483,9</td><td>736 960,0</td></tr>
</table>
Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү</td>
<td>Программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча күрсәткечләр мәгънәләренә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше - 95,641 процент, шул исәптән:<br>2019 ел - 92,8 процент;<br>2020 ел - 92,8 процент;<br>2021 ел - 93,6 процент;<br>2022 ел – 94,2 процент;<br>2023 ел – 95,641 процент;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2024 ел – 95,641 процент;<br>үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкының өлеше - 98,782 процент, шул исәптән:<br>2019 ел - 96,1 процент;<br>2020 ел - 96,0 процент;<br>2021 ел - 96,8 процент;<br>2022 ел – 97,3 процент;<br>2023 ел – 98,782 процент;<br>2024 ел – 98,782 процент;<br>Төбәк программасы чаралары яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга һәм халыкның яшәешенә ярдәм итәчәк.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләү VIII бүлектә китерелгән»; |

Төбәк программасының III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының агымдагы торышына сыйфатлама, Татарстан Республикасында эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә торган чаралар тасвирламасы

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча, 2021 елның 1 гыйнварына торышы буенча Татарстан Республикасында су үткәргеч челтәрләрнең озынлыгы 18,57 мең км тәшкил итә, шуларның 5,93 мең км (31,93 процент) алмаштырырга кирәк, су белән тәэмин итү челтәрләренең тузуы - 49,3 процент.

Чиста су булмау халыкның сәламәтлегендә чагыла һәм йогышлы авырулар таралу, авыруларны үстерү, төрле факторларның кешенең организмына йогынты ясау куркынычы дәрәҗәсен арттыру сәбәбе булып тора. Барлык авыруларның 20 процентка якыны суның канәгатьләнерлек булмаган сыйфаты белән бәйле булырга мөмкин.

2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларының торышын бәяләү йомгаклары буенча (инвентаризация) үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлеше 93,58 процент тәшкил итте, шул исәптән:

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән шәһәр халкы өлеше – 96,79 процент;

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән авыл халкы өлеше – 82,09 процент;

Төбәк программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында эчәргә яраклы суның сыйфатын яхшыртачак 7 чараны башкару планлаштырыла, шул исәптән:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе». Болгар шәһәрендә эчәргә

яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проект гамәлдәге су җыю җайланмасының җитештерүчәнлеген арттыруны һәм тәүлегенә 5 мең кубометр проект куәте булган су үткәргеч чистарту станциясе төзүне күздә тота. Суны эчә торган сыйфатка кадәр чистарту өчен, гадиләштерелгән аэрация белән кайнар фильтрлар кулланып, бербаскычлы чистарту кабул ителде.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 8 476 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,218 процентка арттырып.

2. «Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше». Васильево шәһәр тибындагы поселогында эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проект белән тәүлегенә 4 мең кубометр проект куәте булган су әзерләү станциясен төзү каралган. Суны эчәргә яраклы сыйфатка кадәр чистарту кире осмос җайланмасында алга таба зарарсызландыру белән каралган.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 17 341 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,445 процентка арттырып.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү». Нурлат шәһәрендә поселогында эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проектта Чирмешән чыганагы территориясендә Чулпан авылы янында скважиналар бораулау, насос станцияләре төзү, тәүлегенә 10 мең куб метр су әзерләү куәте белән су әзерләү станциясенә кадәр суүткәргеч салу каралган. Суны эчәргә яраклы сыйфатка кадәр чистарту алга таба зарарсызландыру белән тирән аэрация булган ашыгыч фильтрларда каралган.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 32 703 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,84 процентка арттырып.

4. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Белоус авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү»; Проектның максаты - Тукай районының төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан торак пунктларны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү. Моның өчен «Челныводоканал» ҖЧҖнең су чистарту станциясеннән алып «Түбән Кама» милли паркы территориясенә кадәр ике торба белән исәпләгәндә 13,2 км суүткәргеч төзү каралган.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 7 810 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,201 процентка арттырып.

5. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү». Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Проект белән сәгатенә 42 мең кубометр проект куәте булган су әзерләү

станциясен төзү каралган. Суны эчәргә яраклы сыйфатка кадәр чистарту схемасы утырма фильтрлар төенендә эзлекле фильтрацияне һәм алга таба йогынтыны зарарсызландырып кире осмос урнаштыруны күздә тота.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 11 735 кешене эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү планлаштырыла, «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше» максатчан күрсәткечен 0,301 процентка арттырып.

6. 9 070 пог.метр озынлыкта «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Суровка һәм Новотроицкое авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү». Проектны гамәлгә ашыру Чаллы шәһәрендә «Белоус» су алу җайланмасыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән Тукай муниципаль районының Суровка һәм Новотроицкое авылларында яшәүче тиешенчә 1 939 һәм 2 297 кешене тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы Татарстан Республикасы халкы өлеше» максатчан күрсәткеченең мәгънәсен 0,109 процентка арттырачак.

Барлык чаралар Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештерелә.

7. Шулай ук программа кысаларында чаралар Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе акчалары исәбеннән «Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесен су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системалары объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү» объекты буенча гамәлгә ашырыла.

1 нче таблица

Төбәк программасы чаралары

| Т/с | Чара исеме | Объектны эксплуатациягә керткәннән соң үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү система-ларыннан сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин ителгән халык санының артуы, мең кеше | Объектны эксплуатациягә керткәннән соң үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү система-ларыннан сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин ителгән халык өлеше, процент | Эчәргә яраклы суның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми торган күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше» | 17 341 | 0,445 | суның катылыгы, тимер, марганец һәм башка күр-сәткечләрнең гомуми күләме норматив күрсәткечләрдән артып китә»; |
| 2. | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре өчен су җыю үзәге булган су белән тәэмин итү системасын төзү» | 32 703 | 0,840 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе» | 8 476 | 0,218 | |
| 4. | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Белоус авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү» | 7 810 | 0,201 | |
| 5. | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясен төзү» | 11 735 | 0,301 | |
| 6. | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Суровка һәм Новотроицкое авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү» | 4 236 | 0,109 | |
| | Барлыгы | 82 301 | 2,114 | |

Төбәк программасының IV бүлегендә:

икенче абзацта «95,03» саннарын «95,641» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «98,34» саннарын «98,782» саннарына алмаштырырга.

бишенче абзацта «биш» сүзен «алты» сүзенә алмаштырырга;

җиденче - егерменче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкының өлеше - 95,641 процент, шул исәптән:

2019 ел - 92,8 процент;

2020 ел - 92,8 процент;

2021 ел - 93,6 процент;

2022 ел – 94,2 процент;

2023 ел – 95,641 процент;

2024 ел – 95,641 процент;

үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкының өлеше - 98,7 процент, шул исәптән:

2019 ел - 96,1 процент;

2020 ел - 96,1 процент;

2021 ел - 96,8 процент;

2022 ел – 97,3 процент;

2023 ел – 98,782 процент;

2024 ел – 98,782 процент.»;

Төбәк программасының VI бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Төбәк программасын ресурслар белән тәэмин итү

2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 2 248 668,75 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы акча | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 80 444,72 | 4 822,0 | 20 556,82 | 55 065,9 |
| 2020 | 54 134,45 | 0,0 | 0,0 | 54 134,45 |
| 2021 | 274 548,27 | 26 391,58 | 112 510,88 | 135 645,81 |
| 2022 | 897 207,07 | 148 018,98 | 631 028,3 | 118 159,79 |
| 2023 | 755 357,19 | 107 992,29 | 460 387,9 | 186 977,0 |
| 2024 | 186 977,05 | 0,0 | 0,0 | 186 977,05 |
| Барлыгы | 2 248 668,75 | 287 224,85 | 1 224 483,9 | 736 960,0 |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

Төбәк программасының VIII бүлегенең 2 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтинг-та позиция | Чара исеме | Татарстан Республикасы халкының гомуми санына китерелгән үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлешен арттыруның план күрсәткече, процентлар | Федераль бюджеттан инвестиция-ләр күләме, мең сум | Бюджет нәтиҗәлелеге, сум/процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 = 4/3 |
| 1. | «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы тәүлегенә 5 мең куб метрлы Болгар шәһәре су алу станциясе реконструкциясе» | 0,218 | 20 556,82 | 94 297 340 |
| 2. | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы | 0,301 | 42 611,3 | 141 565 780 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | поселогында су әзерләү станциясен төзү» | | | |
| 3. | «Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында су әзерләү станциясе төзелеше» | 0,445 | 112 510,875 | 252 833 426 |
| 4. | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Суровка һәм Новотроицкое авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү» | 0,109 | 59 767,4 | 548 324 771 |
| 5. | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә су белән тәэмин итү өчен су җыю үзәге төзү» | 0,84 | 784 787,5 | 934 270 833 |
| 6. | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Белоус авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү» | 0,201 | 204 250,0 | 1 016 169 154»; |
| Барлыгы | | 2,114 | 1 224 483,895 | |

Төбәк программасының IX бүлегенең бишенче - җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елда - 118 159,79 мең сум;

2023 елда - 186 977,0 мең сум;

2024 елда - 186 977,05 мең сум.»;

Төбәк программасына 1 нче – 5 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин